Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ | КАРАР

15.04.2024 ел Менделеевск ш. №247

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фаразлау планына (Программасына) үзгәрешләр кертү турында.

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2005 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, Менделеевск муниципаль районы Советының 2016 елның 30 декабрендәге 240 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында» нигезләмәләре нигезендә

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. «2024 елга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2024 елның 05 февралендәге 236 номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертергә һәм «Ачык аукцион сатуларда сатылырга тиешле Менделеевск муниципаль районының күчемсез мөлкәтенең исемлеге» 1 нче кушымтасын 1 нче таблицада, түбәндәге мөлкәт белән тулыландырырга:

| № т/б | Объектның исеме, билгеләнеше | Урыны (адресы) | Гомуми характеристика кв.метр. |
|---|---|---|---|
| 1 | Торак булмаган бина - Камай авыл советы<br>Кадастр номеры 16:27:030104:100 җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Камай авыл җирлеге, Камай авылы | 96,0 |

| № т/б | Милек атамасы | VIN код | Чыгарылыш елы | дәүләт номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | DAEWOO NEXIA автомобиле | VIN WB3L32EDDA017092 | 2012 | Р 499 МЕ |

2.Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.ru “Норматив документлар” бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Совет рәисе : Р.И.Беляев